ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 3-11-18, факс: (84379) 3-11-18.

19.11.2022 № 3

На №__________ от__________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Савино авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?- Савино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау,

«ӘЙЕ» «ЮК»

дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 19 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 47 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 24 кеше кертелгән. Җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 24 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылында халык җыены булды дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Савино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау, дигән сорау буенча карарны таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләрен Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Д. В. Морозов